ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

06.04.2020　　　　№ 196

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 гыйнварындагы 58 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль законга, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законга (2018 елның 3 августындагы үзгәрешләр белән), "Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 27.06.2009 елдагы 151-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (2019 елның 2 августына үзгәрешләр белән), Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында 29.05.2009 елдагы 116-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексына күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә үзгәрешләр кертү турында 2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 гыйнварындагы 58 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтаның 1,5 п. 4 абзацында; 2 нче кушымтаның 1.5 п. 5 абзацында; 2 нче кушымтаның 2.5, 2.6, 3.4.1пунктларына; 2.9 пунктының 3, 4 нче пунктчаларына; 2 нче кушымтаның 1.1, 2.1, 2.3 пунктларына 3.5.1 п. 2 абзацына; 1 нче кушымтага, 2 нче кушымтага; 3 нче кушымтаның 2.9 пунктындагы 5 пунктчасына; 2 нче кушымтаның 2 нче кушымтасында “торак бинаның” сүзләрен «күпфатирлы йорттагы биналар» сүзләренә алмаштырырга ";

3 кушымтаның 2.5 пункта түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктлар белән тулыландырырга:

"6) күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышының торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы турында карар үз эченә алган беркетмәсе;

7) күчерелә торган бинага якын булган барлык биналарның һәр милекчесенең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы..";

1нче кушымтадагы 2нче бүлекнең п2.5пунктының 3, 4 пунктчасында

3 пунктның беренче абзацында “проектлы” сүзен “әлеге Кодексның 48 статьясындагы 15нче өлеше нигезендә расланган проектлы" сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта "капиталь төзелеш объектының проект документларына экспертиза бәяләмәсе" сүзләрен "капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, шул исәптән әлеге проект документациясе белән, линияле объектларны да кертеп, башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта, проект документларына экспертиза бәяләмәсе" сүзләренә алмаштырырга";

1 кушымтаның 2 бүлегендәге 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4_2 һәм 4_3 пунктлары өстәргә:

"4_2) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы һәм әлеге зат тарафыннан расланган проект документларына нигезләнгән һәм әлеге кодекс нигезендә архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча белгеч булып торучы зат тарафыннан әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3_8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Проект документларына әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3_8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;

4_3) әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3_9 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, башкарма хакимият органы яисә проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3_9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;";

1 нче кушымтаның 1.5 пунктының 7 абзацында "бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән тәртипләр" сүзләрен өстәргә .

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов